КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 апрель г.Казань № 303

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 25 май, 352 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 25 май, 352 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның унсигезенче – егерме бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Урта-Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе;

җирле үзидарә органнары;

Система операторы;

диспетчерлык үзәге;»;

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ташучылар.»;

2.1 пунктта:

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлында күзәтчелек идарәсенә» сүзләрен «Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Урта-Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның икенче һәм өченче абзацларында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» заменить сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин